**УКРАИНА МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ ИДӘРӘСЕ**
Духовное управление мусульман Украины

# Мәүлид Ән-Нәбий

Мүхаммад Пәйгамбәребез хакында касыйдәләр
Мохтасар (кыскартылган)

**өченче басма**

**Киев–2007**

Данная книга «Мәүлид Ән-Нәбий» – о времени рождения последнего Пророка Мүхаммада, мир Ему,
**на татарском языке**

С вопросами, пожеланиями и замечаниями обращайтесь в редакцию издательства «Аль-Иршад» по адресу:
✉ 04071 Киев, ул. Лукъяновская, 46
☎ (044) 465-18-77, 465-18-78, факс: (044) 456-17-70,
www.islamyat.org, E-mail: islam@i.kiev.ua

**Читайте наши книги:**

- Серия «Истинный путь»:
книга *1* — «Вера мусульманина».
книга *2* — «Таhарат».
книга *3* — «Намаз».
книга *4* — «Рамадан».
книга *5* — «Хадж».
книга *6* — «Закят».
книга *7* — «Путешествие и вознесение Пророка».
- «Твердость в убеждениях».
- «Нравственность и культура в Исламе».
- «Вопросы и Ответы» (содержит более четырехсот вопросов по религии и ответов к ним. Объяснение книги “Мухтасар“).
- «Мухтасар» (содержит большинство из необходимых знаний по Исламу, как вопросы веры, мусульманское право (фикh), некоторые правила деловых отношений между мусульманами).
- «Истинный Путь» (содержит полное объяснение **‘акыда** (правильных убеждений и веры)).
- «Мавлид Пророка». О праздновании Дня рождения Пророка.
- Серия «Детям о Кор’ане. История наших предков».
- Серия «Детям об Исламе. Исламская культура». (5 кн.)
- «Избранные пятничные проповеди».
- «Осторожно, экстремизм».
- «Никах. Некоторые разъяснения вопросов бракосочетания по Шари’ату».
- «Заблуждения ваhhабитов» (источник краткой информации об этом течении. Аргументов против опасности, которая исходит от этого течения).

**Издание третье**

**Книга набрана и сверстана издательством «Аль-Иршад» при Духовном управлении мусульман Украины**

الإرشاد

✉ 04071 Киев, ул. Лукъяновская, 46
☎ (044) 465-18-77, 465-18-78, факс: (044) 456-17-70,
www.islamyat.org, E-mail: islam@i.kiev.ua

## КЕРЕШ СҮЗ

Аллаһ Тәʻаләгә барча мактаулар вә шөкерләр булсын!
Безнең сөекле Пәйгамбәребез Мүх̲әммәдкә – Салава́т!

Исла́м – бөтен Пәйгамбәрләрнең Дине.

Исла́м – бердән-бер хак Ди́н!

Хаерле эшләр кабул булсын өчен иң беренче шарт – дөрес иман. Вә иманыбыз дөрес булсын өчен без Динебезне өйрәнергә тиешбез.

Хөрмәтле укучылар, Диний мәгълүмәтләргә игътибарлы булыгыз! Исла́м буенча иң кирәкле белемнәр алырга ашыгыгыз! Чөнки, белмәгән кешенең үзенә һәм якыннарына күп зарар китерүе бар!

Алла́һ Тәга́лә́нең Әмерләрен җиренә җиткереп үтәрлек вә гөнаһ-хаталар кылмаслык кадәр гыйлем өйрәнергә кирәк.

Иң элек: Алла́һ Тәга́лә́нең барлыгын вә берлеген, бер кемгә дә мохтаҗ булмаганын, бер нәрсәгә дә охшамаганын, һич бер урында булмаганын белү һәм хәзрәти Мүх̲әммәд (Саллэлла́һу ʻаләйһи үә сәлләм) – Алла́һның илчесе булуын кабул итү тиешле.

Вә Пәйгамбәребезгә Алла́һ Тәга́лә́дән иңгән мәгълүмәтләрне без кабул итәргә тиешбез.

Һәм иман белән бергә Шәһә́дәт кәлимәсен тел белән әйтү – Исла́м Динебезнең төп шартларның берсе.

Шәһә́дәт кәлимәсе:

أَشْهَدُ أَن لاَّ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَ أَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدٌ رَسُولُ اللهِ

«Әшһәду әл-лә́ илә́һә иллэлла́һу
үә әшһәду әннә Мүх̲әммәдәр-расу́лүлла́һ»

Мәгънәсе: Мин Шәһә́дәт кәлимәсен әйтәм ки: Алла́һтан башка Тәңре юк, вә Шәһә́дәт кәлимәсен әйтәм ки: Мүх̲әммәд – Алла́һның илчесе!

Шәһә́дәт кәлимәсен тел белән әйтеп, мәгънәсен кабул иткән кемсә мөэмин-мөселман булыр һәм Исла́м Динен тоткан булыр.

Шундый мөселман гөнаһлардан үзе теләп, чын күңелдән сакланса һәм Алла́һның Әмерләрен җиренә җиткереп үтәсә – иманы кувәтләнер, нығыр, сәләмәтләнер. Бу кеше тәква́ иясе булып исәпләнер һәм газапсыз Җәннәткә керергә лаек булыр.

Алла́һ Тәга́лә́ Корьәнне Мүх̲әммәд Пәйгамбәребезгә иңдергән вә бөтен колларына Исла́м Ди́нен тотарга әмер иткән. Һәм өч төрле көфердән сакланырга кушкан. Вә Пәйгамбәребез га́ләмнәргә рәхмәт булып килгән һәм эшләгән эшләре белән Корьәндәге әмерләрне үтәгән, сүзләр белән аны аңлаткан.

Шуның өчен Алла́һ Тәга́лә́нең иң сөекле колын – хәзрәти Мүх̲әммәдне сөю – Иманның бер шартыдыр. Аңа булган сөю арту белән мөэминнәрнең иманы да артыр, Дине кувәтләнер. Ул Алла́һның әмерләрен белдерде һәм бөтен акыл ияләренә үрнәк булып яшәде. Аның тормышын өйрәнгәннән соң Ул бөек Пәйгамбәргә хәйран калмау һәм Аны сөймәү мөмкин түгел.

Исла́мны аңлату юлында Пәйгамбәребез бик күп авыр җәфалар чиккән, төрле җәбер-золымнар күргән, әмма каршысында сабыр итеп, чыдамлы вә түземле булган. Бу хәлне ишеткән һәм белгән бик күп кешеләрнең Исла́м Динен кабул итүләре билгеле. Без – мөселманнар, мондый бөек Пәйгамбәрнең өммәте булганга Алла́һ Раббыббызның бөек нигъмәтенә ия булабыз. Моның кадерен белергә һәм Алла́һ Тәга́лә́гә шөкер итәргә кирәк. Алланы сөйгән – Аның әмерләрен дә сөя.

Мөселманнар борын заманнардан ук хәзрәти Мүх̲әммәдкә булган сөюләреннән Пәйгамбәребез турында күп шигырьләр һәм касыйдәләр язганнар. Хәзрәти Мүх̲әммәд хакында гарәпчә, төркичә вә башка телләрдә төрле мәүлидләр укыганнар. Бу күркәм эш әлегә хәтле дә югалмаган, безнең заманыбызда да дәвамлы укылып тора. Әмма төрки телләрдә сөйләшкән халыклар арасында иң мәшһүр булган һәм дә шушы кавымлар арасында бик күп хөрмәт ителеп, биш гасырдан бирле, йыш укылган һәм таралган Мәүлидне Сөләйман Чәләби язган, аның исеме «Мәүлиди Шәриф» булган. Шушы Мәүлидне кайсы-бер Балкан вә Кавказ мөселман кабиләләр да үз телләренә тәрҗемә итеп укыганнар. Шул Мәүлидне Сөләйман Чәләби тирән иманы һәм хәзрәти Мүх̲әммәдкә карата булган бөек мөхәббәтеннән тырышып язган.

Ошбу язучы – Сөләйман Чәләби Госманлы падишаһлар заманында булган беренче башкаласы Бурсада 1350 елда туып, шул ук шәһәрдә 1422 елда вафат иткән (кояш тәкъвимы буенча).

Алла́һның рәхмәте Пәйгамбәребез Салләлла́һу ʻаләйһи үә сәлләмгә, Аның га́иләсенә, дусларына – Саха́бәләренә, вә мөэмин-мөселман кардәшләребезгә булсын!

Безнең сөекле Пәйгамбәребез Мүхәммәдкә – Салават!

Аллаһ Тәʻалә Мүхәммәд Пәйгамбәребезнең дәрәҗәсен күтәрсен!

Мөхтәрам Дин кардәшләребез!

Бу китапны сезгә Украина мөселманнары Диния идәрәсе тәкъдим итә.

Бу эшнең төп макъсаты – Ислам Дине гыйбәдәтләрне һәм мөселманнар гореф гадәтләребезне үзгәртмиче саклау, өйрәнү вә якыннарга, балаларга өйрәтү.

Вә шушы китапны махсус татар телендә чыгардык – төрки телләрне белүче халыклар аңласын өчен.

Аллаһ Тәʻалә безнең тырышуыбызны кабул итсен вә барыбызга да күп файда бирсен!

Аллаһка шөкер, безнең әби-бабайлар Хак тугъры Динебезне тоттылар, сакладылар, Аллаһ Тәʻалә аларны рахмәт әйләсен!

Һәм без – мөселманнар барыбыз да бергә бабайларыбызның хак юлда булырга тиешбез. Ә бугенге көннәрдә күп терле-терле фиркъалар мәйданга килеп чыкты инде. Алар юлыбызны бозып, азып, безне адаштырыр өчен эш алып баралар. Аларның арасында бик нык мәшһүр булганы – ВӘҺҺӘБИләр, төрле хизбләр – партиялар, “хизб ат-тахрир”, “джамаат исләмийяһ” исемле.

Шушы кешеләр безнең кыйммәтле гореф-гадәтләрне инкяр итәләр, мәсәлән, Мәүлид үткәрүгә каршы киләләр, мөселман мәетләребезгә Коръән уку-укытудан тыялар, балаларыбызны безнең бөек Имам Әбу Ханифа буенча укытудан мәхрүм итәләр һәм башка галимнәр вә остазларны мыскыллап, мәсхәрәләп, мәшһүр булган дүрт Мәзһәбләрне инкяр итәләр, танымыйлар. Намаз укымыган кешегә алар уйламыйча "кяфер" диләр. Бетү тагудан тыялар, борынгылар үткәргән мәҗелесләргә каршы килеп, мәетләребезгә Коръән укытуны да файда бирми – диләр. Андый бозыклыктан ерак булыгыз!

Аллаһ Тәʻалә мәдәд биреп, сабырлык, түзем вә изгелек нәсыйп итсен!

Тагын бер ноктада кирәк иде туктарга, игътибарыгызны сорарга – әлеге кайсыбер китапларда Пәйгамбәребез турында ялган язалар, мәсәлән, әйтәләр Ул нурдан диеп, дөреслектә, нур дигән сүз – Пәйгамбәргә Пәйгамбәрлек килүен аңлата, шул турыда Пәйгамбәрлек нуры диелә.

Кайсыбер кешеләр Аллаһ исемен бозып "Алла" диеп әйтәләр, ә кайсылары: "Аh" диеп кыскарталар – бу да ярамаган гөнаһ булган эш.

Аллаһ Тәʻалә Корьәндә әйтте, мәгънәсе: "Аллаһның Исемнәре иң гүзәл (ямле)". Шуңа курә, Дин кардәшләр, кирәкле Дини белем алып, гөнаһларга батудан ерак булырга кирәк!

Һәм шушы китап барыбызга да күп файда биреп, Хак Динебезне тотар өчен ярдәм итәр диеп өметләнәбез!

---

Украина мөселманнары Диния идарәсе
Духовное управление мусульман Украины
Киев, ул. Лукьяновская, 46. тел. 38044-4651877

## “Мәүлид Ән-Нәбий” хакында

## МӘҮЛИД ШӘРИФ ҮТКӘРҮНЕҢ ТАРИХЫ

Пәйгамбәребез Мүхәммәд Мустафа́ Салләлла́һу ʻаләйһи үә сәлләмнең туган көнен ачык билгеләп вә шул көндә фәкыйрь-мескеннәрне ашатып, садакалар биреп шатландыру, Пәйгамбәребезнең тууы вә үсүе хакында гарәпчә вә төркичә бәян ителгән касыйдәләрне уку борон заманнардан ук бик ачык беленде.

VII гасырда бик юмарт Ирбил падишаһы Мә́лик Мозаффар Әбу́-Сәгы́йть Кәүкәбрий ибн Зәйнуд-Ди́н ʻАли́ ибн Бәктәкин бик мәшһүр булган Касийу́н тауда “Әль-Җә́миг-Әль-Музаффәрий” исемле зур мәчет төзегән, һәм 630 елны ʻАккә шәһәрендә мөселманнарны залимнәрдән коткарды. Шушы Мозаффәр падишаһ бик тугъры вә гадел кеше булган.

Ул Пәйгамбәребезгә зыйада мөхәббәтеннән һәм юмартлыгыннан ошбу “Мәүлид Шәри́ф касыйдәсе” не укытырга булышты, ашлар хәзерләп, күп халыкны туйдырырга юл ачты, күп ихсан

вә тәсаддык кылуларны мәйданга чыгарып, һәр ел “Мәүлидин-Нәбий көне” голәма́-и вә мәшәйх һәм күп фәкыйрләрне җыеп, зур аш мәҗлесләре ясап, “Мәүлид Шәри́ф касыйдәләр” укучыларга һәм голәма-и вә мәшәйхләргә яхшы вә гүзәл киемнәр кидереп, бик күп мал сарыф кыла иде.

Аның өчен Шәех Әбүль-Хатта́б ибн Дихья́ үзенең “Әт-Тәнви́р фи́ Мәүлид Әль-Бәши́р Ән-Нәзи́р” дигән китабында Мәүлиднең эчтәлеген язып бирде.

Мәүлид үткәрүнең яхшылыгын бик күп галимнәр тәсдикълап әйттеләр: Әль-Хә́физ Әхмәд ибн Хәҗәр Әль-‘Аскалә́ний, Әль-Хә́физ Әс-Сахравий, Әль-Хә́физ Әс-Сүю́тый.

Пәйгамбәребез Фил елында, Раби́гыль-Әүвәл аеның уникесендә туды – ул дүшәмбе көне иде вә Ул әйткән иде: “Мин туган вә миңа Пәйгамбәрлек иңдерелгән көн!” – диеп ураза тотарга кушкан иде.

Хасыйлә: Расу́лүлла́һ туган көнен без генә түгел – бик белемле кешеләр Мәүлид укып уздырганнар, шуңа күрә безгә дә бу эш бик яхшы вә сәваплы булыр.

---

Украина мөселманнары Диния идарәсе
Духовное управление мусульман Украины
Киев, ул. Лукьяновская, 46. тел. 38044-4651877

Бисмилләһир-рахмәнир-рахыйм

**Пәйгамбәребез Мүхәммәд ‘аләйһис-сәлә́мнең шәмәиле**

Пәйгамбәребез әдәмиләр арасында иң күркәм холыклысы иде һәм юмартрагы вә баһадиррагы иде.

Вә әдәмиләрнең иң күркәм сыйфатлысы вә гүзәле иде. Буе исә уртача, озынга маил иде, иңбашлары киң иде. Чәче вә сакалы бик кара һәм куе иде, керфекләре озын иде. Йөзе нурлы иде, вә ак тәнне иде ки, аклыгы кызыл белән катыш, кызылга маил иде. Йөрегән вакытта җиңел йөрер иде.

Пәйгамбәребез бик оялчан иде. Вә Ул һәртөрле авырлыкларга сабыр кылучы иде.

Расүлюллаһның Пәйгамбәрлек Хатимы-Мөһре аркасында күгәрчен йомыркасы хәтле миң кебек иде.

“Мәүлидин-Нәбий” не укучыларга, тыңлаучыларга вә аны укытырга ярдәм итүчеләргә Аллаһ Тә‘алә Мәхшәр Көнендә Пәйгамбәребезнең Шәфәгатен насыйп кылса иде, вә куркыныч хәлләрдән имин кылса иде. Әми́н!

## Расу́л Әкрәмнең нәсәб шәрифе

Бисмилләһир-рахмәнир-рахыйм.

Дүртесенең исемен белмәк важип.
Әһле ихсән санадылар ап-ачык.

Габдулла́һ иде Мүхәммәд атасы.
Габдуль-Мутталиб иде һәм бабасы.

Һә́шим иде ул баба өченчесе.
Габду Мәнәф булды тәмам дүртесе.

Габду Мәнәфнең атасы – Кусай
Кусай – Зәйд улы, Зәйд – Киля́б улы,
Киля́б – Мурраһ улы, Мурраһ – Кя‘аб улы,
Кя‘аб – Люәй улы, Люәй – Га́либ улы,
Га́либ – Фиһр улы, Ул – Курайш кабиләсенең атасы,

Фиһр – Мә́лик улы, Мә́лик – Ән-Надр улы,
Ән-Надр – Кинә́нәһ улы, Кинәнә́һ – Хузәймәһ улы,
Хузәймәһ – Мудрикяһ улы, Мудрикяһ – Илья́с улы,
Илья́с – Мудар улы, Мудар – Низә́р улы,
Низә́р – Ма‘ад улы, Ма‘ад – ‘Аднә́н улы,
Аннан соң Пәйгамбәребезнең нәсәбе Ибра́һи́м улы Исмә́гы́йлгә тоташа.

Пәйгамбәребезнең әнисе Ваһб кызы Ә́минә.

---

Украина мөселманнары Диния идарәсе.
Духовное управление мусульман Украины.
Киев, ул. Лукьяновская, 46. тел. 38044-4651877

# Беренче БАБ

Әввәле мин бер хикаять әйтәем,
Әһле ахбәрдән риваять итәем.
Бар иде Багдатта бер сали́ха,
Габида хатын иде һам на́сыйха.
Беркөн ул дөньядан теләде сәфәр,
Дөньяга килгән кеше, шиксез, китәр.
Анасыннан бер фелур мирасы бар,
Җәннәткә кермәк булсын иде карар!
Бар иде бер изге улы – яшь егет,
Тагать үзрә булыр иде һәрвакыт.
Ул фелури калды мирас улына.
Диер иде: “Ни алыйм мин моңа?”
Уйлый-уйлый йөрегәндә ул егет,
Күп кешегә очрады ул шул вакыт.
Мәүлид укыйлар җыелып бер өйдә,
Бу егет тыңлады һәм ихләс илә.
Ишетеп үк гашыйк булды бу егет,
Күзләреннән акты яшьләр чишмә тик.
Ул егет курде төшендә шул төнне –
Гуя улмыштыр Кыямәтнең Көне.
Чакыра фәрештә: “Кил!” – диеп шул заман.
“Кайда син? Кил, Җәннәткә кер, әй, фәлән!
Мәүлидтә хазер булганнар һәм дәхи
Җәннәткә алар керсеннәр һәммәсе!
Күрде шунда бу егет бер зур Сарай,
“Кертсәгезче мине монда?!” – дип сорай.
Диделәр: “Монда керә шундый кеше –
Хөрмәт итсә ул Нәбий туган көнне,
Хөрмәт иткәнең синең юк ул көнне!” –
Дип, кире дүндерделәр ул мескенне.
Йокысыннан уянып күп еглады,
Күңелене әһак уты чорнады.
Иртәгәсен ул фелургә алды аш,
Мәүлид укытты тугебән каты яшь.
Ул егет Мәүлид укытты ел саен,
Шатланып көтәр иде Мәүлид аен.
Көлә-көлә Ахыйраткә күчте ул.
Чын әҗәлнең мәңге суын эчте ул.
“Үлмәгәндер ул!” – диде каумы аның,
“Чөнки Газраил җиңел алды җанын!”
Бер табиб китерделәр тизлек белән,
“Җаны чыкмыш, – диде ул, – рахмәт белән!”
Каумы диде: “үлмәгән дә үлмәгән!”
Чөнки җан чыкканын һичкем белмәгән.
Күрделәр ки: ул егет ифрат матур,
Нуры балкыр, мисле Җәннәт эчрә Хур.”
Табиб диде: “үлгәнендә шөбһә юк,
Хак Нәзир кылмыш аңа рахмәтен күп!”
Шул вакытта күзен ачты ул үзе,
Диде: “Каумым, тыңлагыз бу сүземне!

Җәннәт эчрә урнымны күрдем хәзер,
Мустафа мәҗлесендә булдым хәзер.

Иткән өчен Мәүлиденә хөрмәтен,
Хак Тәга́лә́ кылды миңа рәхмәтен.”

Көлгәнем будыр минем, белгел, – диде,
Кылыгыз Туган көнен хөрмәт, – диде.

Шулай диде, күзләрен йомды янә,
Каумы калды шатланып – көлгәненә.

Ул Хәби́бнең хөрмәт өчен, и́, Ганий,
Кыл Шәфә́гатен нәсыйп, Син, и́, Вәлий!

И́, Мүхәммәд Мустафа́, Син, и́, Расу́л,
Кыл Шәфә́гать безләргә Йәүмүн-Нузу́ль!

****************

**САЛАВАТ**

****************

---

Украина мөселманнары Диния идарәсе
Духовное управление мусульман Украины
Киев, ул. Лукьяновская, 46. тел. 38044-4651877

**САЛӘВАТ**

الصلاة و السلام عليك　　　يا رسول الله
الصلاة و السلام عليك　　　يا حبيب الله

الصلاة و السلام عليك　　　يا خليل الله
الصلاة و السلام عليك　　　يا نبي الله

الصلاة و السلام عليك　　　يا صفي الله
الصلاة و السلام عليك　　　يا خير خلق الله

الصلاة و السلام عليك يا سيد اللأولين و الأخرين
و صلوا على جميع الأنبياء و المرسلين
والحمد لله رب العالمين

**САЛӘВАТ (транскрипция)**

Әссолә́ту үәс-сәлә́му, ‘аләйкә, Йә́, Расу́ләллаһ́.
Әссолә́ту үәс-сәлә́му, ‘аләйкә, Йә́, Хәби́бәллаһ́.
Әссолә́ту үәс-сәлә́му, ‘аләйкә, Йә́, Хали́ләллаһ́.
Әссолә́ту үәс-сәлә́му, ‘аләйкә, Йә́, Нәбийәллаһ́.
Әссолә́ту үәс-сәлә́му, ‘аләйкә, Йә, Сафийәллаһ́.
Әссоләту үәс-сәләму, ‘аләйкә, Йә́, Хойра Халькыллә́һ.
Әссолә́ту үәс-сәлә́му, ‘аләйкә,
Йә́, Сәййдаль-Әүвәли́нә үәль-Ә́хири́н.
Үә соллу́ ‘алә́ джәми́ыль-Әнбия́-и үәль-мурсәли́н.
Үәльхәмду лилләһ́и роббиль-‘а́ләми́н.

**Икенче БАБ**

Бисмилләһир-рохмәнир-рохыйм.

Әүвәл Аллаһ Исемен яд итәем,
Соңра, хәерле эшкә керешәем.
Эш башында һәркем Аны яд итәр,
Ул эшне Аллаһ аңа асан итәр.
Аллаһ Исеме белән эш башламак,
Изге икәнен тиештер аңламак.
Булса Аллаһ Исме берлә яхшы эшең,
Бушка китмәс эшләгән изге эшең.
Шуны кыла, “Аллаһ!” дисә кем теле,
Түгелер гөнаһлары яфрак кебек.
Пак булыр Хак Исемен яд әйләгән,
Ирешер максудына – “Аллаһ” дигән.
Чын күңелдән килегез: “Аллаһ” – дийек,
Күзебездән яшь түгеп без әйтиек.
Йә, Аллаһу, йә, Аллаһу, йә, Аллаһ,
Йә, Аллаһу, йә, Аллаһу, йә, Аллаһ.
Шулай кылсак, буш куймас Аллаһ безне,
Рәхмәте киң, ярлыкасын Ул безне!
Бердер Аллаһ, берлегенә шөбһә юк,
Сөйләгәннәр яңлышып – дөнья тулык.
Барча галәм юк икән, Ул бар иде,
Та әзәлдән бай иде, Җәббар иде.
Җен-Фәрештә һәм Адәм – берсе дә юк,
Һәм, янә, тугыз фәләк – һичберсе юк!
Гарше-Күрсий, Ай-Кояш һәм юк иде,
Барча җаннан әүвәл үк Ул бар иде.
Көдрәт илә буларны бар әйләде,
Берлегене барча икрар әйләде.
Бу хосуста күп сүзгә хаҗәт тә юк,
Бер вә Бар Аллаһ – Халик – Ул, башка юк.
Гәр шәфәгать лязем исә, эзләгез,
Ул Расүлнең Сөннәтеннән бизмәгез.
И, Мүхәммәд Мустафа, Син, и, Расүл,
Кыл Шәфәгәть безләргә Йәүмүн-Нузүль!
*****************

САЛАВАТ

*****************

И, Газизләр, инде килде сүз башы,
Тыңлагыз әле агызыб күз яшен.
Бер вәсыять сөйләмәкче буламын,
Ул вәсыять ошбудыр, тот колагың,
Һәркем аны тыңласа, тотар исә,
Ул кешедән һәрзаман хушбуй исә.

***** шушы вакытта хушбуй сөртелә *****

Кылыр Аллаһ ул кешегә рахмәтен,
Мәүлидин-Нәбийнең кылса хөрмәтен.
Тыңлаганнар һәм табар фазаилен,
Укыр исә инсабан шәмәилен.
Рухыны шат идәлем Саләт илә,
Әһле бәйте барча Әсхәбләр илә.

Тугдыгы көннәрене хөрмәт иткән,
Тыңлар ул кыйсасыны ихләс белән.
И́, Мүхәммәд Мустафа́, Син, и́, Расу́л,
Кыл Шәфә́гәть безләргә Йәүмүн-Нузу́ль!
*******************
САЛАВАТ
*******************
Хак Тәга́лә́ чын яратты Ә́дәмне,
Кылды Ә́дәмлә мөзәййән галәмне.
Сәҗдә кылды һәр Фәрештә Ә́дәмгә,
Әммә иблис сәҗдә кылмады Аңа.
Диде: “Балчыктан яраттың Син Аны,
Ни өчен сәҗдә кылыйм Аңа?” – диде.
“Мине уттан Син яраттың, бит!” – диде,
“Ут мы артык, яки балчык мы?” – диде.
Шунда ук иблис ул тәкәбберләнде,
Алла́һның Әмерен ул үтәмәде,
Шуннан ук иблис кяфер булып калды,
Наданнарны ул хактан адаштырды
Га́ләмгә рахмәт белән килде Расүл,
Тугры юлны аңлатты һәр вакыт Ул.
Гәр шәфә́гать лә́зем и́сә, эзләге́з,
Ул Расу́лнең Сөннәтеннән бизмәгез.
И́, Мүхәммәд Мустафа́, Син, и́, Расу́л,
Кыл Шәфә́гәть безләргә Йәүмүн-Нузу́ль!
*********************
САЛАВАТ
*********************
Ә́минә ханым – Мүхәммәд анасы,
Ул сәдәфтән тугды энҗе данесе.
Ул – Мүхәммәд дөньяга тәшриф итәр,
Вакыт иреште кильмәгә хойруль-бәшәр.
Инде Аның килүе булды анык,
Күп галәмәт заһир булды аннан ук.
Ул Рабиг‘ыль-әүвәл аенда иде,
Уникенче кичә – дүшәмбе – диде.
Диде: “Күрдем” – ул Мүхәммәд анасы,
Бер гаҗәп нур, нәкъ кояшның яктысы!
Ялт итеп чыкты өемнән шул заман,
Күкләргә тик нур белән тулды җиһан.
Һәм һава үзрә түшәлде бер түшәк,
Аты – Сүндус, түшәгән аны Мәләк.
Өч аләм дәхи тегелде өч җиргә,
Аралары бик ерак бер-берийә.
Берсе – мәшрикъ, берсе мәгърибтә аның,
Бересе – нәкъ уртасында Кәгъбәнең.
Белдем аннан ул мөбарәкнең нурын,
Заһир булды килмәсеннән әүвәлин.
Инде күктән күп фәрештә сафы-саф,
Кәгъбә кебек кылдылар өйемә тауаф.
Заһир булды дәфгатән өч хур кызы,
Билгеле булмады кайдан килгәнне.
Өчеседә яныма утырдылар,
“Мустафа килә!” – диеп гәп ордылар.

Диделәр: “Углың кебек хөрмәтлене
Ул Хода һичбер анага бирмәде!
Бик олог дәүләт иясе буласың,
Холкы күркәм бер угыл тугдырасың!
Бу угыл гыйлемледән солтанидыр,
Бу угыл Тәүхидә гыйрфән кянидер.”
Васфыны шул рәсмә тәртип иттеләр,
Ул мөбарәк нурны тәргыйп иттеләр.
Диде Әминә: “Вакыт җитте тәмам,
Килә инде дөньяга Хойруль-әнам.
Эсселектән сусудым гаять каты,
Шул вакыт эчерделәр бер ширбәтне.”
*******************
Ширбәт эчерәләр.
*******************
“Ак иде, кардан дәхи салкын иде,
Бу кебек тәм дөньяда һич юк иде.
Эчтем аны, барча әгъзам булды нур,
Эчемә дә, тышыма да тулды нур.
Килде бер аккош канат илә очып,
Карнымы сыйпады ул, монда төшеп.
Тугды әүвәл сәгатьтә Ул – Солтан Дин,
Нурга гарык булды сәмәүәт-зәмин.”
Гәр шәфәгать ләзем исә, эзләгез,
Ул Расүлнең Сөннәтеннән бизмәгез.
И, Мүхәммәд Мустафа, Син, и, Расүл,
Кыл Шәфәгәть безләргә Йәүмүн-Нузүль!
***************
САЛАВАТ
***************
**ЙӘ, ХОДАДАН ЛӘТИФ-ИХСАН ЭСТӘГӘН**

Йә, Ходадан ләтиф-ихсан эстәгән кил, Мәүлидә!
Җәннәт эчрә хуру гилмен эстәгән кил, Мәүлидә!
Ул Расулнең туган көне бик бөек кичә иде.
Һәм шулай ук йөзе нурлы Ай кеби балкыр иде.
Җан вә дилдән чын күңелдән тыңларга, Мәүлидә кил!
Үлгәнеңчә дөньяда сагь – тыңларга, Мәүлидә кил!
Укылырса Мәүлиддә махсус касыйдә һәр заман.
Ул Расулнең рухы хушнуд булачактыр бел, һаман.
Гәр шу мәжлесә идәләрсә сине дәгъвәт белән,
Бер даккъа торма, элек кит, калма ялкаулык белән.
Ни кадәр шөгълең булса да, ки куеп кил мәҗелесә.
Иштиракъ ит, син, шәфәгәт рөэяи күр бу кичә.
Җәннәти Әгъләдә Мәкам теләрсәң – Мәүлидә кил!
Хәүз-Кәүсәрдән эчмәгә эстәсәң – син Мәүлидә кил!
Тиз Сиратны кичмәгә эстәр исәң, Мәүлидә кил!
Һәм шәфәгәт өмет итсәң ашыгып, Мәүлидә кил!
Әй, Кәрим! (Аллаһ) Син, Җәннәткә керт, без гасый бәндәләрне,
Һәм Үзеңне курергә насыйп ит, Син барчабызны.
Гәр шәфәгать ләзем исә, эзләгез,
Ул Расүлнең Сөннәтеннән бизмәгез.
И́, Мүхәммәд Мустафа́, Син, и́, Расу́л,
Кыл Шәфә́гәть безләргә Йәүмүн-Нузу́ль!
*****************

САЛАВАТ
******************

## МӘХӘЛЛӘ КЫЯМ

Расүлүлла́һи саллэлла́һу ʻаләйһи үә сәлләм туган вакытын искә алганда (зикер иткәндә), аяк өстенә басып, Салават шәрифне уку – голәмаи-кирам каршында бик күркәм эш булганнан, алар, хосусан, Хәромәйни-шәрифәйни голәмәләре бу урында аяк үзрә торып, Салават шәриф вә сәлам укыдылар. Түбәндәге бәетләрне аяк үрә торып укырга яхшы.

**Туды бу айда Расүлебез Мүхәммәд Мустафа,**
**Яудырабыз без бу көн тәбрик сәламын Аңа.**
**Каршылыйбыз бу мөкаддәс айны без шатлык белән,**
**Бер авыздан әйтәбез һәм: Мәрхәбә, йә Мәрхәбә!**
**Һәм әйтәек: "Йә, Расүләллаһ!" Сәләмнәр бездән Сиңа!**
**Бу мөкаддәс көнне котлап, Мәрхәбә, йә Мәрхәбә!**

**Яратылмыш барча мәхлук булды шат,**
**Кайгылар китте галәмнән, калды саф.**
**Җөмлә зәррате җиһан итеп сәда,**
**Чакрышып диделәр: "Кем, мәрхабә!**
Мәрхабә, и, гали солтан, мәрхабә!
Мәрхабә, и, кәне гыйрфан, мәрхабә!
Мәрхабә, и, күррәтуль-гайнель-хәлил!
Мәрхабә, и, хассы мәхбүбе Җәлил!
Мәрхабә, и, жүмләнең мәтлүбе син!
Мәрхабә, и, Халикъның мәхбүбе син!
Мәрхабә, и, Җаны-җаннан, мәрхабә!
Мәрхабә, и, дәрдә дәрман, мәрхабә!
Мәрхабә, и, гасый өммәт мәлҗәи́!
Мәрхабә, и, чәрасызлар әшфәʻый!
Мәрхабә, и, рахмәтүллиль-галәмин!
Мәрхабә, и, Син шәфиыль-мүзнәбин!
И, Җәмәле, көн йөзе, бәдре мүнир!
И, куму дүшәннәрә Син дәстәгир!
И, күңеллә дәрдәнең дәрманы Син!
И, яратылмышларның солтаны Син!
И, Мүхәммәд Мустафа, Син, и, Расүл,
Кыл Шәфәгәть безләргә Йәүмүн-Нузүль!
******************
САЛАВАТ
******************
Мәккә халыкның олуглары рәвах,
Кылдылар Кәгъбәне бер кичә тауаф.
Күрделәр Кәгъбә янында тавыш-гам,
Диделәр: "Кем, туды ул Хайруль-әнам!"
Кәгъбәтуллаһтан ишетелде сәда,
Диде: "Туды бу кичә Нуруль-һуда!"
Яланаяк, башы ачык, сафы-сафы
Итәчәк өммәтләре шунда тауаф.
Пакъ итеп поттан-кяфердән ул Расүл,
Коткарыр Кәгъбәне мөшрикләрдән ул!"

Фәхре галәм килде кырык яшенә,
Ул Нүбүввәт таҗын киде башына.
Иңде Коръән Аять-Аять бәййнәт,
Заһир булды ничә төрле могҗизат.
Ул мөбәрак башы үзрә бер заман
Күләгәләп бер болыт йөрде һаман.
Ул Мүхәммәднең туган көн кичәсе
Тулды нур белән бөтен дөнья дәхи.
Шәүләсе итте аның Шамда зоһур,
Әһле Мәккә күрделәр, кем, юк косур.
Сүнде фәрәс мәгъбүдененң утлары,
Чыкты дәхи ул Бохәйра сулары,
Күп гаҗәеп могҗизалар күрделәр,
Тугдыгы көнне икәнен белделәр.
Фәхре галәм тугдыгыйлә барча җан:
“Күп бәшарәт безгә, – диделәр, – һаман!”
И, Мүхәммәд Мустафа, Син, и, Расүл,
Кыл Шәфәгәть безләргә Йәүмүн-Нузүль!
****************

САЛАВАТ

****************

Украина мөселманнары Диния идарәсе
Духовное управление мусульман Украины
Киев, ул. Лукьяновская, 46. тел. 38044-4651877

## Мәүли́дин-Нәбий касыйдәсен укыгач Дога

Алла́һ Тәга́лә́гә мактау-шөкерләр булсын, Йә́, Рабби́, Пәйгамбәребез Мүхәммәднең бөек дәрәҗәсен күтәр!

Йә́, Рабби́, ошбу мәҗлесебездә укылмыш Коръән-и Кәрим вә Салава́т сәвабын Мүхәммәд ‘аләйһис-сәләмнең өммәтенә нәсыйп әйлә! Хосусан Пәйгамбәребезнең туган вакытын бәян әйләгән касыйдәсене укучыларга һәм ерактан вә якыннан тыңлаучы әфәнделәргә вә ханумнарга Пәйгамбәребезнең шәфәгатен насыйп әйлә! Вә барча Дин кардәшләребезгә һәр урында вә һәр вакытта Расүлүллаһи (Саллә́лла́һу ‘аләйһи үә сәлләм) Сөннәтен тотарга вә Аның Сиратенә иярмәккә муафикъ әйлә.

Вә Пәйгамбәребезнең Мәүлид Шәрифен укыган вакытта калебләребезгә риккать вә күзләребезгә яшьләр китереп, Аллаһ Тә‘аләдән Шәфәгатьне сораганда, Йә, Рабби, безгә бөек Пәйгамбәребез Шәфәгатен насыйп ит!

Йә́, Рабби́, Пәйгамбәребезнең бөек Рух Шәри́фен шат әйлә вә җөмлә әһле-бәйтен вә а́ли вә асха́б вә голәмә́и-кира́м вә мөҗтәһиди́н-гыйзә́м әрва́х таййибәләренә һәдийябезне вәсыйль әйле! Ошбу хәерле мәҗлесебездә хәзердә булган барча мөэмин-мөселман кардәшләребезнең иман белән дөньядан киткән ата-аналарга, әби-бабайларга, барча кавым-кабиләләргә һәм туган-ырулар рухларга васыйль әйлә!

Вә киләчәк заманнарда да шушы мәҗлес кебек хәерле мәҗлесләрне күрергә вә үткәрергә мөәссир ит!

Йә́, Рабби́, безгә күркәм холык вы изге эшләр кылырга муәфикъ әйлә. Йөрәкләребезгә – нык иман, җаннарыбызга – тынычлык, тәннәребезгә – рәхәтлек, тормышыбызга – җиңеллек бир.

Изге вә хаерле тормышлар яшәр өчен безгә хәлал кәсепләр алырга, хәлал ризыклар ашарга нәсыйп әйлә!

Йә́, Робби́, дөньяда һәм әхирәттә изгелек вә хәерлесен бир! Безгә вә балаларыбызга тәүфикъ-һидәять бир, хәерле гомерләр нәсыйп әйлә.

Йә́, Рабби́, безне бәла-казалардан, шайтан вә дошман шәрреннән имин кыл, яман күздән вә яман сүздән сакла!

Ахыр сулуыбызда иманыбызны юлдаш кылып, иң соңгы сүзләр: “Лә́ илә́һә иллә́лла́һу Мүхәммәдүр-расу́лүлла́һ” – кәлимә-и таййибәсе белән дөньядан чыгып, хөсни ха́тимә нәсы́йп әйлә́!

Әу́зү билләһи минәш-шәйто́нир-рожи́м. Роббәнә́ ә́тинә́ фид-дүнья́ хәсәнәтән, үә филь-ә́хыроти хәсәнәтән, үә къынә́ азә́бәннәр. Роббәнә́ лә́ түзигъ къулюбәнә бадә из һадайтәнә́ үә һәб ләнә́ милләдүнкә рохмәтән иннәкә әнтәль-үәһһә́б.

Әмин! Әмин! Әмин!
Бихүрмәти Таһа вә Ясин!

Үәль-хамдү лилләһи раббиль-‘аләмин.

Аллаһ ризалыгы өчен, Пәйгамбәребезнең шәфәгате нәсыйп булсын өчен, изге Догаларыбыз кабул булсын өчен –
Әл-Фә́тихәһ!

## ***Ислам динебезне яхшы белегез***

Ошбу гасырда халык арасында Ислам дине турында төрле ялгыш мәгълүматьләр таралган. Кайсыбер кешеләр: “Ислам иң яшь вә соңгы дин”, – диеп уйлылар. Кайсыбер китапларда: “мөселманнар кара ташка табыналар”, – дигән ялгыш фикерне язалар. Тагын бер ялгыш сүзләрдән: мөселманнар Мүхәммәд Пәйгамбәренә генә ышанып, башка Пәйгамбәрләрне танымыйлар вә ышанмыйлар, мәсәлән ‘Иса (рус телендә – Иисус), Муса (Моисей), Ибраһим (Авраам) Пәйгамбәрләр кебекләрне.

Хәзер сезгә Ислам Динебез турында дөрес мәгълүматьләрне тәкъдим итәбез:

“Ислам” сүзе – гарәп теленнән “Бер Аллаһка ышанып, Шәригатьне танып буйсыну” димәктер. Ислам барча Пәйгамбәрләр тоткан Дин булганын аңлата. Шулай ук Ислам Дине – бөтен фәрештәләрнең Дине! Кешеләр яратылганнан элек фәрештәләр Бер Аллаһка ышанып гыйбәдәт кылганнар, Аллаһның Әмерләренә буйсынганнар.

Пәйгамбәрләр кавымнарын Бер Аллаһка ышанып, Шәригатьне үтәргә чакырганнар. Ягъни – халыкларын Ислам Диненә өндәгәннәр. Пәйгамбәрләр төрле кавымлардан булганнар, барысының да милләтләре бер түгел. Соңгы Пәйгамбәр – Мүхәммәд Пәйгамбәребезнең гарәп булганы өчен,

төрле милләтләрдә гарәп теленнән күп дини сүзләр таралган, мәсәлән: “Хәләл”, “Хәрам”, “Ислам”, “Шәригать” һәм башкалар.

“Аллаһ” сүзе – гарәп телендә Яралтучының Исемен аңлата, рус телендә – “Бог”, инглизчә – “God”. Һәрбер телдә “Аллаһ” сүзнең тәрҗемәсе бар.

Кызганычка каршы, кайсыбер кешеләр “Аллаһ” сүзенең мәгънәсен дөрес аңламыйча кулланалар. Алар үзләре “Аллаһ” диләр, әмма башка нәрсәләргә ышаналар вә табыналар.

Без Бердән-Бер Яралтучыны кабул итәбез, Аллаһка ышанабыз. Аллаһ бөтен мәхлүкатьләрне яралтты. Ул барча галәмне юктан бар итте. Шушының мәгънәсе: галәм яралтылганнан элек берни дә юк иде, мәгәр Аллаһ Тә‘алә бар иде. Аллаһ әүвәлсез мәңгелектә бар иде. Аллаһ Үз мәхлүкатьләренә охшамый. Аллаһ Тә‘аләне без мәхлүкатьләр белән чагыштыра да алмыйбыз. Аллаһ барча мәхлүкатьләрдән аерыла.

Күз алдына китереп булган нәрсәләргә Яралтучы охшамас. Бу – безнең иманыбыз.

Без шулай әйтәбез: Аллаһ беркемгә дә, бернәрсәгә дә мохтаҗ түгел, урынга да мохтаҗ түгел. Аллаһның барлыгы урынсыз, һичбер җирдә дә түгел, күкләрдә дә түгел, Ул утырмый. Чөнки Аллаһ Тә‘алә үзгәрми: галәм (дөнья) яратылмастан элек Аллаһ урынсыз бар иде, шул барлыкларны яралтканнан соң Ул шулай ук урынсыз бар, үзгәрмичә, бер хәлдән икенче хәлгә күчмичә. Үзгәрә торган нәрсә – яхшы сыйфатлары яман булып үзгәрә, вә киресенчә: яман булганнан соң яхшыра. Чөнки, үзгәрү – яралтылганның табигате.

Яралтучы Үз мәхлүкатьләренә охшамас, Аллаһның мәхлүкатьләре белән бөтен аермалары бар.

Пәйгамбәрләр турында без шуны әйтәбез: мөселманнар һич шикләнмичә барча Пәйгамбәрләргә ышанырга тиешләр: беренчесе – Адәм ‘аляйһиссәләмнән башлап, соңгысы – Мүхәммәд ‘аляйһиссәләмгә хәтле, вә араларында килгән барча Пәйгамбәрләр белән бергә. Алардан Нух, Ибраһим, Муса, ‘Иса, һәм башкаларны кабул итеп, ышанырга тиешләр.

Ислам Дине галимнәре сөйләве буенча, җир йөзенә Әдәм белән Мүхәммәд арасында бик күп Пәйгамбәрләр килгәннәр. Кайсыбер галимнәр шулай әйттеләр: “Дөньяга 124 мең Пәйгамбәр килгән булган, Аларның арасында 313 Расүл булган”. Без берсен дә калдырмыйча, барча Пәйгамбәрләрне танырга һәм сөяргә тиешбез.

Мәрьям анабызның улы Иса Пәйгамбәр иде, рус телендә – “Иисус сын Марии”, Ул бер үк кеше, төрле кешеләр түгел.

Шул ук Пәйгамбәрләр Исемнәре төрле телләрдә төрлечә әйтелсә дә, барыбер Алар бер үк кешеләр, мәсәлән: Муса (Моисей), Ибраһим (Авраам), Нух (Ной) һәм башкалар.

Пәйгамбәрләр бөтенесе дә Бер Аллаһны белеп, ышанырга өйрәткәннәр.

Аерма шунда гына: төрле заманнарда төрле Шәригатьләр булган (Аллаһның Әмерләре һәм Тыюлары). Вә һәрбер мөселман үзе яшәгән заманындагы Шәригатьне үтәргә тиеш.

Барча мөселманнар Адәм белән Хәүвә беренче кешеләр булганына электән ышанган кебек, шулай ук хәзерге вакытта ышаналар.

Әдәм Пәйгамбәрнең Шәригате буенча туган ир кардәш кыз кардәшенә өйләнер иде. Әмма бер үк карыннан туганнар өйләнмәгәннәр, төрле карыннан туганнар өйләнгәннәр. Кешеләр күбәйгәч ул хөкем үзгәргән. Аннан соң Шәригать хөкемнәре, гыйбәдәт кагыйдәләре үзгәрә торган булган, мәсәлән: көненә ничә мәртәбә Намаз укырга тиешле, кайсыбер Ураза тоту кагыйдәләре, Никәх кылу тәртибе, һәм башка.

Төрле Пәйгамбәрләр төрле вакытларда яшәгәннәр, әмма барысы да кешеләрне Бердән Бер Аллаһ Тә‘аләгә ышанырга өндәгәннәр. Шуны да әйтәсе бар: һәр заман өчен үзгәрмичә калган Шәригать хөкемнәре булган.

Аларның кайсыберләре: хаксыз үтермәскә, урламаска, алдашмаска, зина кылмаска. Пәйгамбәребез ‘аляйһиссәләм әйтте:

«أَفْضَلُ مَا قُلْتُ أَنَا وَ النَّبِيُّونَ مِنْ قَبْلِي لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ»

Мәгънәсе: «Мин вә миннән элек килгән Пәйгамбәрләрнең әйткән иң яхшы сүзләр: “Ля иляhә илляллаh”». Төрле гасырда яшәгән мөселманнар аларга килгән Пәйгамбәрләрне кабул итеп, Аларга ышанып: “Ля иляhә илляллаh”, – сүзләрен әйткәннәр.

Муса Пәйгамбәр заманында яшәгән мөселманнар элегерәк килгән Пәйгамбәрләрне кабул итеп:
«لاَ إِلَـهَ إِلاَّ اللهُ مُوسَى رَسُولُ اللهِ»

“Ля иляhә илляллаh, Муса Расүлүллаһ” – “Аллаһтан башка тәңре юк, Муса Аллаһның Пәйгамбәре”, – диеп әйткәннәр.

‘Иса Пәйгамбәр заманында яшәгән мөселманнар элегерәк килгән

Пәйгамбәрләрне кабул итеп: «لاَ إِلَـهَ إِلاَّ اللهُ عِيسَى رَسُولُ اللهِ»

“Ля иляһә илляллаһ, ‘Иса Расүлүллаһ” – “Аллаһтан башка тәңре юк, ‘Иса Аллаһның Пәйгамбәре”, – дигәннәр.

Әлеге мөселманнар Дөньяга килгән барча Пәйгамбәрләрне кабул итеп, Аларга ышанып:

«لاَ إِلَـهَ إِلاَّ اللهُ مُحَمَّدٌ رَسُولُ اللهِ»

“Ля иляһә илляллаһ, Мүхәммәдүн Расүлүллаһ” – “Аллаһтан башка тәңре юк, Мүхәммәд Аллаһның Пәйгамбәре”, – диялләр. Без барча Пәйгамбәрләрне сөябез, хөрмәтлибез, кабул итәбез, Аларның Пәйгамбәрлегенә ышанабыз. Мөселманнар арасында исемнәре мәшһүр булган Пәйгамбәрләрдән берсенә генә дә ышанмаган кемсә – мөселман түгел, ул – кәфер.

Әгәр берәр кеше: “мин Бер Аллаһка ышанам, вә барча Пәйгамбәрләргә ышанам”, – дисә, әмма Әдәм Пәйгамбәрнең Шәригатен тотарга, әүвәл иңгән кануннарга буйсынырга теләсә – безнең заманада шундый эш кабул булмый.

Безнең заман – яңа. Әле – Ахыр заман Пәйгамбәрнең вакыты. Хәзер яңа хөкемнәр, яңа Шәригать, шуңа күрә, һәр мөселман Мүхәммәд Пәйгамбәрнең Шәригатен тотарга вә буйсынырга тиеш. Буйсынмаса, ышанмаса – Шәригатьне инкәр иткән булыр. Беркайчан да дини сүзләрне үзгәртеп әйтергә ярамый, гарәп телендәге дини терминнарны дөрес әйтергә лязем. Аллаһның исемен үзгәртеп, хәрефләрне бозып, авазларны хата белән әйтергә ярамый, мәсәлән: кайсыбер кешеләр ялгышып шулай әйтәләр: “Аллаг”, “Аллах”, “Алла”, “Аллага”.

Вә кайсыбер кешеләр “Мүхәммәд” исемен әйткәндә, хата ясап: “Мохамед”, “Магомет”, “Мага” – диеп, кимсетәләр, Шулай әйтергә ярамый. Пәйгамбәребезнең исемен дөресләп: “Мүх̱әммәд”, – диеп әйтү кирәк, я дә: “Әбүл-Касим”, чөнки Пәйгамбәребезнең Касим исемле улы булган.

Кем чын күңелдән: “ Лә Иләһә илляллаһ, Мүх̱әммәд – Расүлүллаһ” – “Аллаһтан башка тәңре юк, Мүхәммәд – Аллаһның илчесе (Пәйгамбәре)”. Я шушы мәгънәле башка сүзләрне әйтсә – мөселман булыр.

Әгәр берәр кеше шулай әйтсә: “Иса этисез туганга күрә – Ходайның улы ул”, – дисә, андый кешегә без шулай аңлатабыз: без ышанабыз Иса Пәйгамбәргә дә, Муса Пәйгамбәргә дә, әмма алардан элек Әдәм Пәйгамбәр яшәгән булган, Аның хатыны Хәүвә исемле хатын иде.Барча Пәйгамбәрләр бер хак Динне танучылар һәм алып баручылар. Алар барчасы да Бер Аллаһка ышанып Ислам Динен өйрәткән булганнар. Барысы да: “Кыямәт Көне киләчәк”, – диеп өйрәткәннәр. Җәннәт һәм Җәһәннәм барлыгы турында сөйләгәннәр. Пәйгамбәрләр барысы да Аллаһтан вәхий алганнар. Барысы да: “Аллаһ бернигә дә мохтаҗ түгел”, – диеп өйрәткәннәр, шуңа күрә Аллаһ беркемгә дә мохтаҗ булмагач – угъылга да мохтаҗ түгел.

Кайсыбер кешеләр әйтәләр: “кемнең улы булса – шуның оныгы да булуы мөмкин, онықларның уллары вә абый-апалары булуы мөмкин һәм башка”. Бу акылга сыймый торган эш, киресенчә, Аллаһ – Бердән-Бер Яралтучы, Ул беркемгә дә, бернәрсәгә дә мохтаҗ түгел, Аллаһка охшаш вә тиңдәш юк. Аллаһ Тә‘алә Мәрьям ханумны башка хатыннардан аерып, өстен кылды, Мәрьям анабыз – дөнья хатыннары арасында иң изге һәм әүлия.

Мәрьям җенси якынлык кылмыйча йөкле булды вә улын тудырды. Аллаһ өчен бернәрсә дә авыр түгел, бу – Аллаһтан һәдия, шатлык. Аллаһ Әдәм вә Хәүвәне эти-әнисез яралтты. Әдәм, аляйһиссәләм сабый бала булып яралтылмады. Аллаһ Тә‘алә Әдәмне җир туфрагыннан зур кеше итеп яралтты. Хәүвә исә Әдәм Пәйгамбәребезнең кабыргасыннан шулай ук, бала түгел – зур кеше булып яралтылган. Мәрьям анабыз үзе этиле-әниле булып туган һәм үскән, әмма Иса Пәйгамбәр – этисез туган, якынлык кылмастан.

Калган кешеләр ир белән хатын якынлык кылганнан соң дөньяга киләләр. Кыямәт көнендә кешеләр каберләреннән чыгарлар, тәннәре черегәннәрнең дә тәннәре яңадан җыелыр. Әмма беркем дә әйтмәс: “без тумадык, шуның өчен Аллаһның уллары”, – дигән сүзләрне.

Аллаһ Тә‘алә кешеләргә Үз Кодрәте чиксез булганын аңлатыр өчен, Тәңре – һәрнәрсәнең Яратучысы булганын аңлатыр өчен – Мәрьям анабызга шундый нигъмәт биргән ки: ир белән якынлык кылмыйча Мәрьям бала тапкан, Иса Пәйгамбәрне тудырган. Әмма Мәрьям анабыз – ул Аллаһның бәндәсе, Аллаһның әнисе түгел. Иса Пәйгамбәр дә шулай ук – Аллаһның бәндәсе, илчесе. Иса Пәйгамбәр Аллаһның улы түгел. Безнең Динебез акылга каршы килми һәм шуны раслый, дөрес күрә.

Әгәр берәр кем: “кешеләр элек маймыл булып яралтылганнар”, – дисә, ул гипотеза бернинди асылсыз, дәлилсез, гыйлем һәм акыл белән тәсдикланмаган.

Ислам Дине – һич яңа дин түгел, бөтен Пәйгамбәрләр бер хак Динне тотканнар, барысының да бер үк ышанулары, иманнары булган. Алар барчасы да Бер Аллаһ Тәʻаләгә ышанып торганнар, Аллаһка тиңдәш юк, охшаш юк, диеп өйрәткәннәр.

Әгәр кеше шул мәгълүматьләрне аңласа, аңа ышанса, шундук Исләм Диненә керер өчен туктамыйча таныклык сүзләрен әйтергә кушабыз, таләп итәбез. Һәм шул сүзләр гарәп телендә: “Лә иләһә илляллаһ Мүхәммәд расулюллаһ”, мәсәлән: татар телендә: “Аллаһтан башка Тәңре юк, Мүхәммәд – Аллаһның илчесе”, рус телендә: “Нет Бога кроме Аллаhа, Абуль-Гасим – Его Пророк”.

Я дә шул мәгънәне бирә торган башка сүзләрне әйтсә дә була, гарәп телендә әйтәлмәсә, башка телдә әйтсен.

Кеше мөселман булмастан: “мин ышанам”, – гына дисә, әмма үзе шәһәдәт сүзләрен әйтмәгән булса, андый кеше мөселман булмый, ул кәфер булып кала, таныклык сүзләрен әйткәнче.

Берәр кәфер Ислам Динен кабул итәр өчен дөрес мәгълүматьләрне белеп, шуңа ышанып, Ислам Шәһәдәт сүзләрен (таныклык сүзләрен) әйтергә тиеш.

Берәр кеше Ислам Динебезнең турында белеп, Ислам Динен кабул итәргә әзер булса, аны кичектерергә ярамый, бер сәгаткә дә, бер минутка да ярамый. Андый кеше Ислам Динен кабул итәр өчен мөселман янына килсә, ә шул мөселман: «соңгарак кил» я дә: «көтеп тор, имам юк әле», я дә: «минем эшем бар», яки: «миңа хөтбәмне сөйләп бетерергә кирәк», я дә: «бар, гөсел ал, аннан соң килерсең», яки: «башта сөннәткә утыр, аннан соң килерсең» һәм башка, андый кеше кәфер булыр, чөнки кешене Исламга керүдән кичектерде, имансыз калуына сәбәп китерде.

Аллаһ аңа риза түгел. Кешенең кайчан үләчәге турында безгә билгеле түгел, бәлки, бер елдан, я дә бер минуттан соң җаны чыгып китәр. Бәлки шул кеше кәфер хәлендә калып, шулай үлер, шуның сәбәбе белән Җәһәннәмгә кереп, анда мәңгегә калыр. Шуңа күрә Исламга керергә теләгән кешене туктатып, аның Исламны кабул итүен кичектерергә ярамый.

Ислам галимнәре әйткәннәр иде: әгәр имам минбардә торып, Вәгазь (Хөтбә) укыган вакытта, аның янына бер кеше килеп: «мин Исламны кабул итәргә телим», – дисә , әмма имам: «хөтбә беткәнче көтәргә кирәк», – дип җавап биргән булса, шундый очракта имам Ислам динебездән чыга, кәфер була.

Берәр кеше Ислам Дине турында белергә я дә сорашырга килгән булса – без аңа иң җиңел ысул белән Динебездә иң кирәкле булган мәгълүматьләрне, Дин асылларын сөйләп бирәбез. Тыңлаган кеше шул мәгълүматьләрне аңлап, кабул итеп, ышанса, шундук Исләм Диненә керер өчен Шәһәдәт сүзләрен әйтергә кушабыз. Аннан шул кешегә Ислам Динебезнең нигезләрен киңәйтеп аңлатырбыз, мәхсус Шәһәдәть кәлимәсенең мәгънәсен тирәнрәк белдерербез. Яңа Ислам Диненә кергән кешеләрне адаштыручы, ялган фикер-ышанудан сакларга тырышырга кирәк. Вә аларны һәрбер мүкәлләф белергә кирәкле булган мөһим вә зарури дини белемне иң кыска вакыт эчендә өйрәтергә тиешле.

---

Украина мөселманнары Диния идарәсе
Духовное управление мусульман Украины
Киев, ул. Лукьяновская, 46. тел. 38044-4651877

## Иманыбыз – иң зур байлык!

Кадерле укучылар! Ислам Динебез – иң зур байлык!

Ислам Динебез – иң зур бәхет! Аны хөрмәт итеп сакларга кирәк. Чөнки Исламнан чыгып кәфер булган кемсәнең гөмер буе тырышып казанган сәваплар юкка чыга, бөтен изгелекләр югала.

Шушындый кеше – бөтен гөмерен гөнаһ эшләүдә генә үткәргән дәен була. Һич яхшылыгы калмый!

Шуңа күрә: без иманның нигезләрен өйрәнеп, иманны боза торган нәрсәләрне дә белергә тиешбез. Иманны көфердән айыра торган мәгълүмәтләр бик мөһим, чөнки Ислам галимнәрнең олыглары әйттеләр: кем гөнаһларны нәрсә икәнен белмәсә – аңа батырга ихтимал зур. Без шул 3 төрле көферлекне кылмас өчен аларны өрәнеп китиек.

# КӨФЕРНЕҢ ӨЧ ТӨРЛЕЛӘРЕ

Көфер – Ислам диненнән чыгу. Динсез калу. Кәфер булу.

Аллаһ Тә‘алә барыбызны да көфердән сакла!

Имам Әгъзам Әбу Хәнифә һәм башка галимнәр әйтүләре буенча көферлек 3 кысымга бүленә: ышануда, гамәлдә һәм сүзләрдә.

*Ышануда* (игътикадтә иман итәргә ярамаган).

*Гамәлдә* (эшләргә ярамаган).

*Сүзләрдә* (тел белән әйтергә ярамаган).

Кардәшлеребез! Мөэмин-мөселман кеше шуны белергә тиеш: имансызлык – иң зур гөнаһ, үлем алдыннан шул гөнаһыннан Исламга кайтып тәүбә итмәгән кешене Аллаһ Тә‘алә гафу итми. Андый кеше – кәфер, Җәннәткә кермәс һәм Җәннәтнең исен дә сизмәс! Шуңа күрә татар халкында иң хурлыклы сүз “имансыз” – дию. Бу гөнаһ кешенен бөтен яхшы-изге гамәлләренең сәвабын юкка чыгара.

*

## *ӨЧ ТӨРЛЕ КӨФЕРДӘН САК БУЛЫГЫЗ!*

**1. Күңелдә көфер.**

Аның урыны – йөрәк. Мәсәлән, Аллаһ Тә‘аләне нәрсәгәдер тиңләү, Аны яктылык яисә рух диеп уйлау, Ул күкләрдә-җирләрдә булып тора диеп уйлау, Ул Гарше өстендә утыручы җисем диеп күз алдына китерү.

Имам Әхмәд ибн Хәнбәл (һижри 174 елда туган) һәм имам Сәубән ибн Ибраһим Зүннүн Әл-Мысрий (һижри 245 йылда үлгән) әйткәннәр: “Аллаһ Тә‘аләне күз алдына китереп булмый, Ул бернигә дә охшамаган”.

**2. Гамәлдә көфер.**

Мәсәлән, белә торып Коръән Кәримне, Яисә Дини язуны вә Аллаһ Тә‘аләнең Исеме язылган кягазьне чүплеккә ташлау, пычырату (нинди телдә язылган булса да).

**3. Тел (сүз) имансызлыгы.**

Шулдыр ки, кем нинди булса Пәйгамбәрне, Фәрештәне, Коръән Кәримне, Кәгъбәне, Ислам Динен хурласа, сүгсә, кимсетсә.

Әйтергә ярамаган мисаллардан: “Алла бабай”, – дияләр.

Кешеләр арасында ишетелгән, дингә каршы булган сүзләрдән: “Алланың сакалы ак”, – диеп, кяфер булалар.

Кайсыберләр Аллаһка тән, кул, аяк, баш, тел, бит кебек әгъзалар кушалар.

Тәкъдирне инкәр итеп, яшь кеше үлсә: “Үз үлеме белән үлмәгән”, – диеп, ялгышалар.

Бик якын туган кеше үлсә, кайсы бер кешеләр Аллаһка: “нигә аның җанын алдың, бу бит гаделсез”, – диеп, Диннән чыгалар.

Шуңа охшаган әшәке сүзләр әйтүдән бик ерак булыгыз!

%

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ، الْحَمْدُ للهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ

وَالصَّلاةُ وَالسَّلامُ عَلَى سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِهِ وَأَصْحَابِهِ الطَّيِّبِينَ الطَّاهِرِينَ

Аллаһ Тә‘алә Исеме белән бөтен яхшы эшләрне башлыйм, Ул – Аллаһ бөтен колларына ошбу дөньяда рәхмәтләр бирә. Әмма Ахирәттә – фәкъать мөэмин-мөселманнарга гына рәхмәтләр бирә.

Җәбер – золым кешеләрнең дөнья ләззәтләрен үлем белән бетергән һәм мөселманнарны явызлардан коткаручы Аллаһка бөтен мактау-шөкерләр булсын!

Аллаһ Тә‘аләнең иң сөекле Пәйгамбәре һәм колы Мүхәммәдкә – Саләүәт!

Йә, Рабби, Мүхәммәд Пәйгамбәребезнең дәрәҗәсен тагын да күтәр!

Йә, Аллаһ, безгә файдалы белем биреп, гөнаһлардан сакланырга вә фарызларны үтәргә көч-күвәт нәсыйб ит!

Тәкъва колларыңнан булырга мөәссәр әйлә!

Аллаһ Тә‘алә Корәндә әйтте (Әль-Хәшр Сүрәсенең 10-че Аяте):

(وَالَّذِينَ جَاؤُوا مِن بَعْدِهِمْ يَقُولُونَ رَبَّنَا اغْفِرْ لَنَا وَلِإِخْوَانِنَا الَّذِينَ سَبَقُونَا بِالإِيمَانِ وَلا تَجْعَلْ فِي قُلُوبِنَا غِلاً لِّلَّذِينَ ءامَنُوا رَبَّنَا إِنَّكَ رَؤُوفٌ رَّحِيمٌ {10})

Мәгънәсе: бер кавым мөселманнардан соң яшәгән башка кавым мөселманнар әйтәләр: "Йә, Рабби, безнең гөнаһларыбызны ярлыка һәм бездән элек яшәгән мөселманнарның гөнаһларын гафу ит, вә мөселманнарга карата йөрәкләребезгә мөхәббәт бир, яман хисләрдән сакла, Йә, Рабби, Син рәхмәт бирүче, мөселманнар өчен хас мәрхәмәт кылучы".

Пәйгамбәребез Мүхәммәд, ‘аляйһиссәләм, әйтте:

[يس قَلْبُ الْقُرْءَانِ لاَ يَقْرَؤُهَا رَجُلٌ يُرِيدُ اللهَ وَ الدَّارَ الآخِرَةَ إِلاَّ غُفِرَ لَهُ، وَ اقْرَءُوهَا عَلَى مَوْتَاكُمْ] رَوَاهُ الإِمَامُ أَحْمَدُ فِي مُسْنَدِهِ.

Ошбу Хәдисне Имам Әхмәд "Муснәд" -ендә риваять итте.

Мәгънәсе: "Йәсин – Коръәррең йөрәге, кем ошбу Сүрәне Аллаһ ризалыгы өчен, ахирәтне макъсат итеп укыса – гөнаһлары гафу ителер. Мәетләрегезгә Йәсин Сүрәсен укыгыз".

Динебез – Ислам: бердән бер хак Дин. Ислам диненнән башка дөрес дин юк! Һәм динебездә иң мөһим булган белем – Аллаһ Тә‘алә турында һәм Пәйгамбәребез Мүхәммәд Мостафа турында мәгълүмәтләр. Шушы гыйлемгә "гыйлм әт-тәүхид" диелә.

Мөселманнарга белергә кирәк булган нәрсәләрдән:

Аллаһ Тә‘алә һич бер нәрсәгә дә мохтаҗ түгел.

Ул барча кимчелекләрдән пакь вә өстен.

Һичбер урында түгел, һичбер тарафта түгел. Аның өсте-асты, уңы-сулы, алды-арты юк. Ул барча мәхлүкатьләргә урын яралтты, Үзе исә урынсыз бардыр. Ул һичбер нәрсәгә охшамаган.

Аллаһ – Бер, Аның тиңдәше юк, Аның охшашы юк, Аның уртагы юк (шәриге юк). Ул – Бер, бүленмәс, чөнки җисем түгел, тәнсез, гәүдәсез. Аның әгъзалары, кысымнары юк.

Аллаһ бөтен нәрсәне күрүче – әмма күз белән түгел! Күрүе яктылыкка мохтаҗ түгел, чөнки Аллаһ Үзе яктылыкны да, караңгылыкны да яралтты – юктан бар итте.

Ул барча тавышларны ишетүче – әмма колак белән түгел!

Аның Кодрәте һәр нәрсәгә җитүче. Әмма кул вә көч белән түгел! Ул арымый, талмый һәм ял итми.

Аллаһның барлыгы әүвәлсез вә ахырсыз.

Ул теләгән нәрсә була, теләмәсә – һичбер нәрсә булмас. Аңа беркем дә әмер бирәлми, вә тыялмый.

Аллаһ һәрбер нәрсәне белүче, әмма өйрәнү белән түгел! Аллаһның белеме артмас, кимемәс һәм үзгәрмәс. Аллаһ һичбер нәрсәне онытмый!

Аллаһ – тередер, әмма тере булганы рухсыз, җансыз, кансыз, йөрәксез, гәүдәсез.

Аллаһ сөйли, әмма тел-теш белән түгел, авыз-үпкә кулланмастан, гарәп-төрки телләрдә түгел. Сөйләүе хәреф-сүз түгел, аваз түгел, җөмлә түгел. Сөйләүе әүвәлсез, ахырсыз һәм туктаусыз.

Кагыйдә шундый: нинди булса фикер белән төшенгән нәрсә – ул яратылмыш, Аллаһ аңа охшамас!

Әмма Пәйгамбәребез Мүхәммәд – Абдуллаһның улы, бабасы – Абдулмутталиб, бабасының әтисе – Һәшим, бабасының бабасы – Абдумәнәф. Гарәпләрнең "Кораеш" дигән кабиләдән. Туды Мәккә шәһәрендә, 40 яшендә вәхий иңде Үзенә, 53 яшендә Мәдинә шәһәренә Һиҗрәт кылды, күчте (руми тәкъвим буенча 622-че йылга якын).

Һәм 63 яшендә Мәдинә шәһәрендә вафат итте.

Без – мөселманнар барча Пәйгамбәрләрне таныйбыз, Аларга эшанабыз. Беренчесе – Адәм ‘аляйһиссәләм, соңгысы – Мүхәммәд солляллаһу ‘аляйһи үә сәлләм. Дөньяга килгән Пәйгамбәрләрнең саны – 124 мең. Барысы да – Ислам Дине белән килделәр, барчасы да мөселман. Алар бөтенесе дә: لاَ إِلَـهَ إِلاَّ اللهُ

"Ля́ иля́һә илляллóһу" – "Аллаһтан башка тәңре юк", – диеп әйтеп йөрегәннәр.

Бөтен Пәйгамбәрләр гөнаһсызлар! Бөтенесе дә мөселманнар!

Һич берсе дә Ислам диненнән башка динне өйрәтмәделәр. Һич берсе дә ай, кояш, йолдыз, ут, потларга табынмаганнар. Тугач ук мөселман булып, үлгәндә дә мөселман булып вафат иткәннәр!

Әмма зур гөнаһлар – зина кылу, урлау кебек, бу эшләргә бер нинди Пәйгамбәр якынлашмады.

Алардан берсе дә Пәйгамбәрлек дәрәҗәсен төшерүче эш кылмаганнар: зур гөнаһ кылу түгел, кечкенә гөнаһларны да эшләмәделәр. Мәсәлән: кешене алдау, рәнҗетү, кимсетү, йөзем бөртеге кадәр нәрсәне урлау.

Шулай ук Пәйгамбәрләр арасында һич берсе дә җирәндерүче чир-сырхау белән чирләмәде. Чөнки шушы мәсъәләдә йыш кына Әййюб Пәйгамбәргә яла ягып әйтәләр: “Ул шундый чир белән чирләгән, Аңардан бөтен халык җирәнеп киткәннәр” – дип, үзләрен гөнаһ-көферлеккә батыралар. Кайсылары тагын да – “тәне черегән” – диләр. Бу да һич дөрес түгел. Шушы кешеләр Әййюб Пәйгамбәрнең чын сабырлыгын күрсәтергә тырышып, Пәйгамбәрләргә лаек булмаган сыйфатлар кушалар. Андый фикер – Ислам динебезгә каршы!

Дөреслектә, Әййюб ‘аляйһиссәләм, бер авыр чир белән чирләгән, ләкин Аның тәне черемәгән, ите гәүдәсеннән айырылып төшмәгән, әмма йөрергә авыр булган, балалары үлгән, малы юкка чыккан. Мәгәр Әййюб Пәйгамбәр сабыр иткән. Аллаһ Тә‘алә үзенә шифа биреп, тагын күп бала вә маллар нәсыйп иткән.

Шуңа күрә Пәйгамбәрләр Аллаһның диненә чакыручылар булып дөньяга җибәрелгәннәр, Аларның төп максатлары – кешеләрне берләштереп Үзләренә оеп, артларыннан барып, Аллаһка ышанырга вә табынырга өйрәткәннәр. Әгәр Аларда кешене куркырлык нәрсә булса иде – кешеләрне Дингә өндәү вазыйфәсе өстләрендә булмас иде, һәм Пәйгамбәр булмаслар иде.

Пәйгамбәрләрнең барысы да бик матур-гүзәлләр: битләре дә, тавышлары да, тәннәре дә, әхлаклары да, сүзләре дә – һәр нәрсәләре йәмле вә чорайлы. Муса Пәйгамбәрнең теле сакау булмаган – Ул сөйләгәндә сүз-хәрефләрне дөрес әйтер иде.

Юсүф Пәйгамбәр бир нинди хатынга шәһүәт күзе белән карамады, чөнки андый бакыш (карау) Пәйгамбәрләргә лаек түгел. Зөләйха – бер вәзирнең хатыны Юсүф Пәйгамбәрне зина кыларга өндәде, тырышты һәм теләп торды, әмма Юсүф Пәйгамбәр ул хатынны этәргә уйлап торганда, Аллаһ Тә‘алә әмер бирде этәмәскә – әйләнеп, борылып яныннан китәргә. Юсүф Пәйгамбәр шул турында төшенгәнен вәһһәбийләр (хак юлдан тайпылган агым, Исламнан чыккан фирка) игълан итеп Пәйгамбәрләргә яла ягалар, ифтиралар атып, Пәйгамбәрләрнең дәрәҗәләрен төшерергә тырышып торалар.

Алар Ибраһим Пәйгамбәрне масхәрәләп: “ай-кояш һәм йолдызларга табынып Аллаһне эзли торган”, – диеп ялган әйтәләр. Бу сүзләрне һичбер Пәйгамбәргә әйтергә булмый, ярамый.

Бу ялганчы ваһһабийләр безнең Пәйгамбәребезне дә: “вәхий иңгәче адашып йөрегән, хакны белмәгән”, дип – Пәйгамбәрлек килгәннән элек “кяфер” булганын иглан итәләр. Безнең иң бөек Пәйгамбәребезне хурлыйлар!

Шушы вәһһәбийләр Аллаһтан курыкмыйлар, Пәйгамбәребездән оялмыйлар!

Без борынгы заманнардан бирле мөселман мәетләребезгә Корьән укытабыз, дога кылабыз, Пәйгамбәребезне хөрмәтләп мәүлид укытабыз. Бу вәһһәбийләр әйтүләре буенча: “кеше үлгәч, аңа башкача бер ни дә файда бирми”, – дияләр.

Корьән вә мәүлид укытуны тыялар, “ярамый”, – диләр.

Шундый мәҗелесләргә хәзеләнгән хәлал итләрне – дуңгыз ите кебек диләр. Мөселманнарга бетү йөретергә ярамый, диләр. Алар Динне бозырга эш алып баралар.

Андый фиркалардан йырак булыгыз. Сак булыгыз!

Безнең мөселман гореф-гадәтләрне бозучыларны тыңламагыз, алар әткән сүзләрне акылыгызга кертмәгез!

%

Украина мөселманнары Диния идарәсе
Духовное управление мусульман Украины
Киев, ул. Лукьяновская, 46. тел. 38044-4651877

# *** СҮЗЛЕК ***

•Асан – җиңел.
•Аты сөндүс – алтын белән чигелгән ефәк.
•Аусаф – холык-сүрәтләре.
•Бинаан – нигез, таяну булган.
•Важип – тиешле.
•Вәлий – олы дәрәҗә иясе.
•Габидә – диндар.
•Ганий – байлык иясе.
•Гасый – бозык, гөнаһлы.
•Голәмәи вә мәшәйх – галимнәр һәм шәехлар – бик күп укыган, белүче һәм өйрәтүчеләр.
•Голәмә-и кәрам – олуг галимнәр.
•Димәктер – диеп әйткән.
•Дәфгатән – кинәттән, көтмәгәндә.
•Заһир – ачык.
•Зыйа – бик нык.
•Идән – иткән.
•Илче – Расүл.
•Инсәбән шәмәилен – нәсел ыру сыйфатлар.
•Ихсан – иманның иң югары дәрәҗәсе.
•Ишетебән – ишетү белән.
•Йәүмүн-Нузүль – Ахирәт Көне.
•Кыйас үзрә – чагыштыру.
•Маил – тартым.
•Мисле Җәннәт эчрә Хур – Җәннәт эчендәге Хур кебек.
•Мәрхабә – хуш килдегез, рәхим итегез.
•Мәсрур кыла – шатландыра.
•Мөзәййән – бизәлеш.
•Мөнәсип күрмәге – тиешле күрүе.
•Мөстәхәб – мактаулы (сәваплы) эш.
•Мөхәддис – Хәдисләрне бик яхшы белүче.
•Мөәссәр – җиңел.
•Нәбий – Пәйгамбәр.
•Нәзир кылмыш – күз салды.
•Нәсәп – нәсел.
•Нәкыйль ителмеш – күчкән, алынган.
•Нәсыйхә – Гыйбәдәтләрне күп кылучы, Диндә үрнәк.
•Ошбу – шушы.
•Рәсмә – рәвешчә.
•Саләват – Аллаһ Тәгаләдән Дога сорыйбәз: “Йә, Рабби, Пәйгамбәребезнең дәрәҗәсен күтәр” – диеп.
•Сабыр – түзем, чыдам.
•Салиха – изге, яхшы.
•Саһил – җиңел.
•Солтандын – солтаннардан.
•Сәмәүәт-зәмин – күкләр-җирләр.
•Та әзәлдән – әүвәлсез, мәңгедән.
•Тик – кебек.
•Тәгъзим итүне – зурлануны.
•Тәргыйп – сөендерделәр, шатландырдылар.
•Тәсаддык – хәер-садака.
•Тәшриф – хөрмәт.
•Тәүхиде гыйрфан кянидер – Бер Аллаһны гына танучы кеше.
•Тәҗәлле – олуглау.
•Тәңре – Иләһ, Аңа гына табынырга, гыйбадәть кылырга була, кем Аллаһтан башкасына гыйбадәть кылса – кяфер була, Ислам диненнән чыккан була.

•Фәза́илен – өстенлекләрен.
•Фәкыйһ – Ислам Динне, Шәригатьне бик яхшы укып белүче.
•Фәхре га́ләм – галәм горурлыгы.
•Фөлүр – тиен акчалар.
•Хазер булыр – катнашыр, килер.
•Хакында – турында.
•Хайрүл-бәшәр – Кешеләрдән иң хәерлесе.
•Хайрүл-әна́м – иң яхшысы.
•Хәби́б – сөекле.
•Хәсы́йлә – моннан бу мәгънә чыга.
•Чагырышыбән – кычкырышып, бөтене бергә.
•Шәһә́дәт кәлимәсе – таныклык сүз: мин беләм, ышанам вә әйтәм.
•Шөкеранасы – Аллаһны мактавы.
•Шәма́ил – күркәм сыйфатлары вә сүрәте.
•Шәри́ф – хөрмәтле.
•Яд идәлем – күңелемә-телемә алам мин (зикер итәм).
•Әзһәре тәшәккүр – халыкка белдереп, күрсәтеп шөкер итү.
•Әзһар әйләде – күрсәтте.
•Әкрам – хөрмәт иясе.
•Әль-хәсыйль – шушы нәтиҗәсендә.
•Әмер – боерык.
•Әүвәле – алдан, элек.
•Әһле бәйте – Пәйгамбәрнең мөселман туганнары.
•Әһле инсан – кешеләр.
•Әһле әхбәр белүче, сөйләүчеләр.
•Әһәк уты – җан көю уты, сафлык уты.
•Җәббар – бар нәрсәгә көче җитүче.
•Җөмлә зәррате җиһан итеп сәда – бөтен галәмнәр тавыш белән, чакырып.
•Һәрдәм – һәрчак.

---

Украина мөселманнары Диния идарәсе
Духовное управление мусульман Украины
Киев, ул. Лукьяновская, 46. тел. 38044-4651877

# ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз ........ 5
“Мәүлид Ән-Нәбий” хакында ........ 13
Расу́л Әкрәмнең нәсәб шәрифе ........ 17
Беренче БАБ ........ 19
Саләват ........ 24
Икенче БАБ ........ 26
Йә, Ходадан ләтиф-ихсан эстәгән ........ 35
Мәхәллә Кыям ........ 37
Мәүлидин-Нәбий касыйдәсен укыгач Дога ........ 42
Ислам динебезне яхшы белегез ........ 45
Иманыбыз – иң зур байлык ........ 60
Көфернең өч төрлеләре ........ 61
Дәрес ........ 64
Сүзлек ........ 74